ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 13 маендагы** **Чистай шәһәре** **№ 231**

“Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 6 июнендәге “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы милкендәге һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләрендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында”гы 294 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында”

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле һәм рациональ файдалану максатларында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы милкендәге һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау хакында”гы 2019 елның 6 июнендәге 294 номерлы карарына түбәндәге редакциядә үзгәрешләр кертергә:

“7. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турында бастырылган мәгълүматны актуальләштерү вәкаләтле орган тарафыннан ел саен 1 апрельдән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла”.

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга - "Чистай хәбәрләре" газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (www.chistopol.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы җитәкчесе М.Ю. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов